СОВЕТ АЛБАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.28, с. Албай,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422176

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АЛБАЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, Албай авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422176

тел.(факс): (85563) 3-05-08; e-mail: Alb.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
№ 3-25

КАРАР
20.06. 2023ел

## Башка шартларда концессион килешү төзү мөмкинлеге турында

«Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы $4^8$ өлеше, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлегендә салкын су белән тәэмин итү объектларына карата концессион килешү төзү турында «Җирлекләргә хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең тәкъдиме нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Советы к а р а р к а б у л и т т е:

1. «Җирлекләргә хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең концессион килешүен төзү инициаторы тәкъдим иткән башка шартларда Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге муниципаль милкендә булган су белән тәэмин итү объектларына карата концессион килешү төзү мөмкинлеге турында карар кабул итәргә.
2. Концессион килешү төзү инициаторы тәкъдим иткән башка шартларда концессион килешү төзү мөмкинлеге турында Карар кабул итүгә бәйле рәвештә концессион килешү шартларын килештерү максатында сөйләшүләр үткәрүнең әлеге карарга теркәлгән тәртибен расларга (алга таба – Тәртип).
3. «Җирлекләргә хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән уртак киңәшмәләр рәвешендә сөйләшүләр алып баруга вәкаләтле эшче төркем төзергә һәм аның кушымтадагы составын расларга.
4. Әлеге эшче төркемгә әлеге карарга кул куелганнан соң 10 (ун ) эш көне эчендә «Җирлекләргә хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән уртак киңәшмәләр рәвешендә концессион килешү шартларын тикшерү һәм аларны тәртип буенча килештерү максатында сөйләшүләр үткәрергә.
5. «Җирлекләргә хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятен башка шартларда концессион килешү төзү мөмкинлеге турында хәбәрдар итәргә.
6. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштырып халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башлыгы И.П. Крешковка йөкләргә.
8. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

Албай авыл җирлеге Советы рәисе,
җирлек башлыгы /И.П. Крешков/

20.06.2023ел № 3-25 карарга
1 нче кушымта

Концессион килешү төзү инициаторы тарафыннан тәкъдим ителгән башка шартларда концессион килешү төзү мөмкинлеге турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә концессион килешү шартларын килештерү максатларында сөйләшүләр уздыру тәртибе

1.Килешүне төзү инициаторы тәкъдим иткән башка шартларда килешү төзү мөмкинлеге турында Карар кабул итүгә бәйле рәвештә концессия килешүе шартларын (алга таба – килешү) килешүне төзү инициаторының вәкаләтле вәкилләре катнашында эшче төркемнең уртак киңәшмәләре рәвешендә үткәрелә (алга таба – сөйләшүләр).

2. Килешүне төзү инициаторы тарафыннан тәкъдим ителгән башка шартларны килештерү турындагы карар эш төркеме тарафыннан кабул ителә һәм сөйләшүләрдә катнашкан барлык затлар тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

3. Сөйләшүләр барышында Килешү шартлары буенча килешүгә ирешелгән очракта, эшче төркем Килешү төзү инициаторына Килешүнең барлык катнашучылар тарафыннан имзаланган шартларын үз эченә алган беркетмәне җибәрә.

4. Сөйләшүләр барышында яклар Килешү шартлары буенча килешүгә ирешмәгән очракта, Мамадыш муниципаль районының Албай авыл җирлеге Советы «Концессион килешүләр турында» 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 4.6 өлешенең 9 пункты нигезендә, имзаланган беркетмә нигезендә сөйләшүләр үткәрү көненнән алып 10 эш көне эчендә, баш тартуның нигезләрен күрсәтеп, Килешү төзүнең мөмкин булмавы турында карар кабул итә һәм Килешүне төзү инициаторына шундый карарның күчермәсен җибәрә.

5. Эшче төркем кертелгән үзгәрешләр белән Килешү проектын алган көннән башлап 3 (өч) эш көне эчендә тапшырылган документларны карый һәм Килешү проектын килештерү йә аны килештерү мөмкин булмау турында карар кабул итә. Эшче төркемнең барлык карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Килешү проектын килештерү мөмкинлеге турында карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән карар Мамадыш муниципаль районының Албай авыл җирлеге советына җибәрелә.

20.06.2023ел № 3-25 карарга
1 нче кушымта

«Җирлекләргә хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән уртак киңәшмәләр рәвешендә сөйләшүләр алып баруга вәкаләтле эшче торкем составы

1. Крешков И.П.- Мамадыш муниципаль район Албай авыл җирлеге башлыгы.
2. Хасанов Р.Р.- Мамадыш муниципаль район «Җирлекләргә хезмәт күрсәтү үзәге» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры
3. Кирушин К.М.- Мамадыш муниципаль район Албай авыл җирлеге Советы депутаты .

ТР Мамадыш муниципаль районы
Албай авыл җирлеге Советы рәисе,
Җирлек башлыгы И.П.Крешков